Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр торак пунктында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 19 нче ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр торак пунктында халык җыены карар бирде:

1. 50% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, ялгыз өлкән пенсионерлардан һәм балигъ булмаган балалар тәрбияләүче гаиләләрдән,Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш,Шеңшеңәр авыл җирлегенең Шеңшеңәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән , балигъ булган һәр гражданга 2023 нче елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Г.Тукай урамы буенча җәяүлеләр тротуарын урнаштыруны дәвам итү;
- Комсомол урамы буенча янгынга каршы гидрант һәм аңа комплектлаучы җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру .

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында,Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе Р.Х.Салихҗанов